РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.08.2017 №161-п

*Саба районында эш алып баручы төзелеш оешмалары коллективларының 2016 елгы эш нәтиҗәләре турында*

Саба районында эш алып баручы төзелеш оешмалары коллективларының 2016 елгы эш нәтиҗәләрен караганнан соң,

КАРАР БИРӘМ:

1. 62 млн. 710 мең сум күләмендә төзелеш эшләре башкарган, районыбызның торак һәм җитештерү объектларын төзүдә зур өлеш керткән, рентабельле эшләүне тәэмин иткән “АК ТАШ” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (җитәкчесе Әхмәтов Г.Г.),

275 млн. 556 мең сум күләмендә юл төзү һәм ремонтлау эшләре башкарган, хезмәт җитештерүчәнлегең арттыруга ирешкән “Татавтодор” акционерлык җәмгыятенең Саба филиалына (җитәкчесе Гарипов М.Г.) беренче урын бирергә һәм коллективларны беренче дәрәҗәдәге Дипломнар белән бүләкләргә.

Җитәкчеләргә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 10ар мең сум күләмендә премия бүләргә.

2. 64 млн. 595 мең сум күләмендә төзелеш эшләре башкарган, районыбызның социаль объектларын төзүгә зур өлеш керткән, рентабельле эшләүне тәэмин иткән “Ремонтстройсервис” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (җитәкчесе Насыйбуллин М.З.) икенче урын бирергә һәм коллективны икенче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 8 мең сум күләмендә премия бүләргә.

3. 37 млн. 346 мең сум күләмендә төзелеш эшләре башкарган, районыбызның социаль объектларын төзүгә зур өлеш керткән, рентабельле эшләүне тәэмин иткән “Акварэй” төзелеш-сәүдә компаниясе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (җитәкчесе Шәрәфетдинов К.Ж.) өченче урын бирергә һәм коллективны өченче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 6 мең сум күләмендә премия бүләргә.

Р.Н. Минниханов